| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

Урман Асты Шонталасы ав.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2021 №2

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең Ар.Баран авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 102 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасыавыл җирлегенең Урман Асты Шонталасыавылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябренә 13:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан АМЙ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Ар.Баран ав, Чернышевский ур., 10А й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Ар.Баран авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына

ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- зиратларны төзекләндерү (материал сатып алу)
- терлекләрнең көтүлекләрен (плотиналарны) төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга ( Ар.Баран халкына җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин**